Каралды: Беркетмә №1
10 сентябрь 2014 ел

Раслыйм:
Мәктәп директоры
Д.З. Садертдинова

# Мөслим муниципаль районы
# Симәк төп гомуми белем бирү мәктәбенең
# «Сердәш» үзидарәсенең Уставы

Симәк, 2014

Мәктәптә балаларны. яшүсмерләрне һәм өлкәннәрне берләштерүче ирекле, үзешчән "Сердәш" оешмасы...

## Оешманың структурасы

- Президент
- Класс командирлары советы рәисе
- Баш мөхәррир

Министрлар

- Мәгариф министры
- Культура министры
- Сәламәтлек саклау министры
- Балаларның хокукларын саклау һәм яклау Информацион-мәгълумат үзәге
- Экология

## Оешманың максаты.

Һәрьяклап үстерүгә булышлык итү, яшь буынны тормышка әзерләү. Татар халкының бай рухи мирасы нигезендә гармонияле, актив эш итүче, иҗади шәхес формалаштырырга омтылу.

## Девизы.

Ватанның киләсе гаҗәеп көннәрен
Тизләтү ягына юнәлттек ниятне.

## Эшчәнлек принциплары.

1. Патриотик һәм батырлык юнәлеше.
2. Мөстәкыйльлек.
3. Милли традицияләргә бай булу.
4. Иҗтимагый әһәмияте.
5. Ирекле лек.

“Сердәш “ оешмасы Мөслим районының Симәк төп гомуми белем бирү мәктәбе базасында оештырылды һәм 5-11 сыйныфта укучы теләсә кайсы укучы аның әгъзасы була ала.

**Оешма ике баскычтан тора.**

1 нче баскыч – 2 -8 сыйныф укучылары- варислар.

2 нче баскыч – 9-11сыйныфукучылары.

## Оешманың традицияләре.

Чисталык традициясе (эчке һәм тышкы чисталык һәр җирдә дә: ашауда да, киемдә дә, күңелдә дә чисталык булырга тиеш).

Дөреслек традициясе ( әмма яңгыравыклы сүзләрдән башка гына).
Яхшылык традициясе ( өлкәннәрне хөрмәт итү, кечкенәләрне кайгырту).
Дуслык традицисе ( Татарстанда яшәүче барлык милләт халыклары белән дә дус яшәү).

## Оешма әгъзаларының хокуклары.

Үзенең фикерен, позициясен ачыктан-ачык әйтә, оешманың эшен тәнкыйтьли, тәкъдимнәр кертә ала. Оешмадан ирекле рәвештә китәргә хокуклы.Оешманың һәр эшендә катнашырга ирекле. Мәктәпнең үзидарә органнарында эшләргә хокуклы.

## Бурычлары.

Оешманың законнарына буйсынырга тиеш. Татар мәдәниятен, телен пропагандаларга, агитацияләргә тиеш һәм яшьтәшләренә аны үзләштерүдә, өйрәнүдә ярдәм итәргә бурычлы. Кечкенәләрнең остазы булсын. Мәктәптә эшләнгән барлык эшләрдә актив катнашырга. Үзен тормышка әзерләргә.

## Бүләкләүләр.

Оешма җәзалау чаралары кулланмый.Ә менә бүләкләүләр түбәндәгечә: әти-әниләргә рәхмәт хатлары, мактау язулары җибәрү, бүләкләр, мактау китабына кертелүләр, мәктәп газетасында мактап телгә алулар, “Сердәш” мактаулар китабына алулар.

## Оешманың структурасы.

Оешманың югары органы булып мәктәп Корылтае санала. Ул елга бер тапкыр май аенда үткәрелә. Корылтайда оешманың советы (берлеге)

сайлана. Совет мәктәп оешмасының эшенә җитәкчелек итә.Һәр чирек ахырында министрлыклар үз юнәлешләре буенча отчётларын бирәләр. Оешмада укучылар тарафыннан башкарылган эшләр дүрт төрле “ үзебез”гә нигезләнергә тиеш:

- ✓ үзебез сайлыйбыз;
- ✓ үзебез уйлыйбыз, планлаштырабыз;
- ✓ үзебез үткәрәбез;
- ✓ үзебез анализлыйбыз.

**Мәктәпнең “Сердәш” оешмасы уставына карата методик киңәшләр.**

“Сердәш” оешмасы Мөслим районының Симәк урта гомуми белем бирү мәктәбе базасында оештырыла. Ул балаларның ирекле иҗтимагый оешмасы. Беркемгә дә буйсынмый, башка балалар оешмаларына бәйле түгел. Оешманың финанс базасы юк, аны мәктәп дирекциясе финанслап тора. “Сердәш”атамасы очраклы гына түгел. “Сердәш” –ул:

- ✓ Татар телен, татар мәдәниятен баету, яңарту, камилләштерү;
- ✓ Татар халкы мирасының чәчәк атуы;
- ✓ Балалар иҗатының, мөмкинлекләренең үсүе;
- ✓ Оешманың әхлакый чисталыгы;
- ✓ Елмаю, оешма әгъзаларының бер-беренә җылы мөнәсәбәте.

**Без нишләргә тиеш?**

**Президент.** Үзидарәнең “җитәкчесе”.Барлык эшләрне дә контрольдә тота.
**Класс командирлары советы.** Һәр класс командиры линейкада рапорт бирә. Класстагы вазыйфаларның үтәлешен контрольдә тота. Чирек саен отчет бирә.
**Баш мөхәррир.** “Белем учагы”газетасын чыгаруга җаваплы.
**Министрлыклар.**
**Культура.** Дәрестән тыш чараларны оештыруда ярдәм итә. Дискотекалар үткәрүдә җаваплы.
**Мәгариф.** Укуга йомгак ясаучы.
**Сәламәтлек саклау.** Иртәнге гимнастикалар ясауны контрольдә тота. Спорт ярышларында катнашуда ярдәм итә.
**Балаларның хокукларын саклау һәм яклау.** Рейдлар үткәрә.
**Информацион-мәгълүматлар.** Укучыларның туган көннәрен билгеләп үтә. Мактаулар китабын даими тутыра.
**Экология**. Укучылар белән табигатькә экскурсияләр оештыра. Мәктәп күләмендә оештырылган экскурсияләрдә урынның чисталыгы өчен җаваплы.